**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 14 апрелендәге 1229 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең**
**2006 елның 6 маендагы 879 номерлы «Казан шәһәре Думасының**
**2006 елның 17 февралендәге 12-6 номерлы “Муниципаль**
**предприятиеләрне һәм учреждениеләрне төзү, үзгәртеп оештыру**
**һәм бетерү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында”гы**
**карары турында»гы карарына**
**үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясенең Хезмәт кодексы нигезендә, Казан шәһәре муниципаль предприятиесе җитәкчесе белән төзелә торган типлаштырылган вакытлы хезмәт килешүен Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 3 ноябрендәге 3330 номерлы «Казан шәһәре муниципаль унитар предприятиеләренең бизнес-планнарын әзерләүне һәм аларны үтәү сыйфатын контрольдә тотуны көчәйтү турында»гы карары белән билгеләнгән бизнес-планнарны эшләү һәм раслау тәртибенә туры китерү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2006 елның 6 маендагы 879 номерлы «Казан шәһәре Думасының 2006 елның 17 февралендәге 12-6 номерлы “Муниципаль предприятиеләрне һәм учреждениеләрне төзү, үзгәртеп оештыру һәм бетерү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында”гы карары турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2009 елның 5 октябрендәге 8329 номерлы, 2010 елның 10 сентябрендәге 8132 номерлы, 2010 елның 31 декабрендәге 11809 номерлы, 2014 елның 5 августындагы 4639 номерлы, 2015 елның 19 ноябрендәге 4023 номерлы, 2016 елның 5 октябрендәге 4049 номерлы, 2017 елның 17 июлендәге 2662 номерлы, 2017 елның 13 октябрендәге 4083 номерлы, 2018 елның 9 августындагы 4427 номерлы, 2018 елның 20 августындагы 4606 номерлы, 2021 елның 1 февралендәге 224 номерлы, 2021 елның 29 мартындагы 741 номерлы, 2021 елның 20 декабрендәге 3420 номерлы, 2022 елның 10 мартындагы 692 номерлы, 2025 елның 26 ноябрендәге 4153 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.

1.1. 3 номерлы кушымтаның 3.1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«3.1.2. Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан расланган Предприятиенең  тиешле елга бизнес-планында билгеләнгән Предприятиенең төп күрсәткечләрен үтәүне тәэмин итәргә»;

1.2. 3 номерлы кушымтаның 3.1.4 пунктын төшереп калдырырга;

1.3. 3 номерлы кушымтаның 4.5 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«4.5. Җитәкчегә эш вакыты һәм ял вакыты режимы, әлеге килешүне исәпкә алып, Предприятиенең эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре нигезендә гамәлгә кертелә.

Җитәкчегә эш вакытының озынлыгы атнага 40 сәгать итеп билгеләнә.

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 115, 125 статьялары нигезендә Җитәкчегә еллык түләүле ял  28 календарь көнне тәшкил итә, ул аңа тулысынча яки өлешләргә бүлеп бирелергә мөмкин.

Еллык түләүле ялга Предприятиедә гамәлдә булган нигезләмә буенча Предприятиенең хуҗалык исәпләве кереме хисабыннан, әмма ике айлык вазифаи оклад зурлыгыннан артмаган күләмдә матди ярдәм түләнә.

Җитәкчегә нормалаштырылмаган эш көне билгеләнә (Җитәкче вазифасы Предприятие хезмәткәрләренең вәкиллекле органы фикерен исәпкә алып кабул ителә торган коллектив шартнамә, килешүләр яисә локаль норматив акт белән нормалаштырылмаган эш көне билгеләнгән вазифалар исемлегенә кертелгән очракта).

Нормалаштырылмаган эш көне режимында эшләгән өчен Җитәкчегә өч календарь көн күләмендә өстәмә түләүле ял бирелә».

2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (А.М.Шайнуров),  Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитетына (И.М.Хисмәтуллин), Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров) әлеге карар кабул ителгәннән алып бер ай вакыт эчендә ведомство карамагындагы муниципаль унитар предприятиеләр җитәкчеләре белән вакытлы хезмәт килешүләренә тиешле үзгәрешләр кертергә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**